**Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены карары**

**12.11.2025**

**№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Шепкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Югары Шепкә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026елда үзарасалымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

1.2. гражданнарның2025 елда җыелган үзара салымыннан калган 98181,80 сум күләмендәге акчаны түбәндәге чараны гамәлгә ашырырга:
- беседка сатып алу.

2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Югары Шепкә торак пунктының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU)

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.